ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘН ҺӘМ БЕЛЕМ МИНИСТРЛЫГЫ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МУНИЦИПАЛЬ БЮДЖЕТ ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ
КИЧКЕТАҢ УРТА ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ МӘКТӘБЕ

*БӨЕК ВАТАН СУГЫШЫНДА ҖИҢҮНЕҢ 70 ЕЛЛЫГЫНА БАГЫШЛАНГАН СОЧИНЕНИЕЛӘР КОНКУРСЫ*

*Номинация: «Истә, һаман да истә...»*

# *Сикәлтәле сугыш юллары*

*(Бөек Ватан сугышында шофер булып хезмәт иткән якташым Муллаян Шәймөхәмәтовның якты истәлегенә )*

*Башкарды: 6 сыйныф укучысы*
*Ибраһимова Динара Флүр кызы*
*Җитәкче: Татар теле һәм әдәбияты укытучысы Шәймөхәммәтова Әлфия Искәндәр кызы*

2014 ел

1941 елның 22 июнендә Бөек Ватан сугышы башлана. Фашист илбасарларына каршы көрәшкә кулына мылтык тота алган һәркем күтәрелә. Безнең Әгерҗе районыннан гына да меңнән артык кеше илне саклаучылар сафына баса. Ни аяныч, шуларның күбесе яу кырында ятып кала. Аларның исемнәре изге китап – «Хәтер китабы»на теркәлгән. Бу китапта халкыбызның горурлыгы, сагышы, йөрәк әрнүе. Әрнү – чөнки һәлак булган каһарманнарны беркайчан да кире кайта- ра алмыйсың. Горурлану хисе – чөнки алар дошман алдында тез чүкмәгәннәр, кешелек тарихындагы иң каты, иң газаплы сугышта чын фидакарьлек күрсәтеп, җиңеп чыкканнар.

Халык хәтере – мәңгелек. «Хәтер китабы» – каһарманнарыбызның исемнәрен мәңгеләштерүче һәйкәл. Анда сугыш кырларында һәлак булган, хәбәрсез югалган, яралардан үлгән якташларыбыз турында мәгълүмат тупланган. Бу китап – туган җирнең азатлыгы өчен башларын салган Татарстан уллары һәм кызларының якты истәлеге алдында яңа буыннарның баш июе билгесе.

Сүзем шул каһарман егетләребезнең берсе, сугыш кырларын айкап, күпме чакрымнар узган шофер егет, якташым Шәймөхәмәтов Муллаян турында.

Шәймөхәмәтов Муллаян Муллахмәт улы 1924 нче елның 1 нче сентябрендә Әгерҗе (элеккеге Красный бор) районы Барҗы авылында колхозчылар гаиләсендә беренче бала булып дөньяга килә.

Әтисе Шәймөхәмәтов Муллахмәт Шәймөхәмәт улы (1902 нче елгы) колхозлар төзелгән вакытта авыл халкыннан атларны кабул итеп ала һәм сугышка киткәнче алдынгы терлекче булып хезмәт куя. Әнисе Минекамалга (1901 нче елгы) авылдашларыннан сыерлар кабул итеп алуны йөклиләр. Ул 35 ел фермада сыер савучы булып эшли, алдынгылыкны бирми.

1941 елның 22нче июнь иртәсе. Кояшлы иртә ни өчендер моңсу да, шомлы да тоела. Бөтен авыл буенча таралган дәһшәтле хәбәр авыл халкын борчуга сала: “Сугыш башланган”.

Сугышның беренче көннәреннән үк Муллаянның әтисен сугышка алалар. Шул китүеннән Муллахмәт хәбәрсез югала. 31 яшьлек Минекамал 5 бала белән тол кала.

1942 нче елның 20 августында Муллаянга да чакыру килә. 1942 нең августыннан алып 1943нең гыйнварына чаклы 6нчы автоуку полкында,, 1943 - 1944 нең октябрь айлары Көньяк-көнбатыш фронтта шофер, 1944тән 1945нең гыйнварынача 12 нче запастагы автополкта, 1945нең гыйнварыннан алып 9 май аена хәтле 704 нче авторотада шәфер буларак хезмәт итә. 1947нче елның март аенда демобилизацияләнә.

Яшь егеткә күпне күрергә туры килә. Сугыш кырында машина йөртү генә түгел, төрле йөкне төяргә һәм бушатырга, өстәвенә куелган вакытка сыешырга, приказны үтәргә, соңга калмаска тиеш булалар. Алгы сызыкка сугыш кирәк-яраклары кертергә, фронттан яралыларны алып чыгарга. Сәгатенә 40 км/сәг тизлек белән генә барырга, бер алга, бер күккә карарга. Күктә ни дә булса күренсә, машинаны яшерергә өлгерергә. Фашист артиллериясе һәм авиациясе бер генә кешене дә, техниканы да күздән ычкындырмаган.

Фронт шоферлары бик авыр, газаплы юллар үткәннәр. Көн-төн чокыр-чакырлы, миналы юллардан, пычрак-саз ерып, кар –буранга карамый күпме чакрымнар үтәләр алар. Ә бит араларында хатын-кыз шоферлар да була. Машинаң чокырга төшсә, ат кебек үзең тартып чыгарасың. Машиналар ватылса, я бомбага эләксә, тиз генә исән калган машинага булган йөкләрне төяп, тагын юлга кузгалалар.

«Сугышта күргәннәрен күз яшьләре аша сөйли иде абыем Муллаян”, - дип искә ала сеңлесе Гөлсинә апа.

Соңрак Муллаян Шәймөхәмәтовка штаб машинасын тапшыралар. Ә бу үтә дә җаваплы. Фронтка, алгы сызыкка баручы офицерны исән-имин илтеп җиткерергә, шулай ук алып кайтырга кирәк. .

Бер баруында машинасы ватыла, запчасть юк. Офицерны башка машинага утыртып җибәрә, үзе машина саклап басуда кала.

Кыш. Суык. Кирәкле запчастьне алып килгәнче, машина кабинасында бер атна яши Муллаян абый. Ашарга юк. Ачтан үлмәс өчен, басуда җыелмый калган өшегән кукуруз белән туклана. Шул вакытта бик нык салкын тидерә.

Хезмәт вакытын тутырып, туган якларына кайткач та, аны ачлык, хәерчелек, авыр тормыш көтә. Әтиләре сугышта югалган, өйдә 4 бала. Әниләре көн-төн фермада эшли.

Муллаян авылына кайткач та машинага утыра. Сугышта күргән михнәт, авырлыклар үзенекен итә. Кайтып 3 кенә ел яшәп кала ул. Авыруы көчәеп, өйләнергә дә өлгермәгән 26-27 яшьлек егет бакыйлыкка күчә.

“Йомшак холыклы, тыныч иде абыем. Аны авыл балалары бик яраталар иде. Эштән кайтуын гына көтеп торалар да, безгә җыелалар. Абыем аларга яшь аралаш сугышта күргәннәрен сөйли иде”, - дип искә ала Гөлсинә апасы.

Еллар узган саен Бөек Ватан сугышы кайтавазы ерагая, ветераннарыбыз да арабызда сирәгәя бара. Тик авыр юллар кичкән, үлем белән күзгә-күз очрашкан , явыз дошманны тар-мар итеп Бөек җиңү яулаган батыр йөрәкле егетләр күңелләрдә мәңге сакланыр.

Туган ил, Ватан өчен кебек сүзләрнең бөеклеген киләчәк буын да аңлап үссен иде. Батырлар үлмиләр, аларның даны үлемсез.

Без – Бөек Җиңү оныкчыклары, илебез күген саклап, батырларча көрәшкән әби-бабаларыбызның данын, изге исемнәрен мәңгеләштерербез. Аларның даны җырларда җырланыр, халык күңелендә мәңге сакланыр.